| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.10.2019 Олы Кайбыч ав. №431

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы
257 номерлы «Кайбыч муниципаль районы авыл
җирлекләренең җирле үзидарә органнары күрсәтә
торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында» Федераль законына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 257 номерлы «Кайбыч муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1,2 нче кушымталарның 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа пунктча өстәргә: «СНИЛС»;

2 нче кушымтаның 1.5 пунктындагы 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адрес - Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары нигезендә структурлаштырылган һәм шул исәптән урам-юл челтәре элементының исемен һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исемен (кирәк булганда), шулай ук адресация объектын идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган цифрлы һәм (яисә) хәрефле-цифрлы билгеләп кую урынын тасвирлау;»;

2 нче кушымтаның 1.5 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән адресация объектлары исемлегендә каралган башка объект;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуник-ацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров